| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Крындинского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Кырынды авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.03.2025 Кырынды авылы № 52-2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елның 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 02.05.2006 елның 59-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елның 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 12.05.2003 елның 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлегендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында кушымтада бирелгән Нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://pravo.tatarstan.ru) веб-адрес буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районның рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) веб-адрес буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районның Кырынды авыл җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Мәүликәев

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге Советының 20.03.2025 елның 52-2 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында Нигезләмә

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге Нигезләмәнең гамәлдә булуы, федераль конституциячел законнарда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиешле мөрәҗәгатьләрдән тыш гражданнарның барлык мөрәҗәгатьләренә кагыла.

1.2. Әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән гражданнарның җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе күрсәтелгән органнар, вазыйфаи затлар тарафыннан гражданнар берләшмәләренең, шул исәптән юридик затлар мөрәҗәгатьләрен карауга бәйле хокук мөнәсәбәтләренә, шулай ук гражданнар, гражданнар берләшмәләренең, шул исәптән гавами әһәмиятле вазыйфаларны үтәүче юридик затларның мөрәҗәгатьләрен карауга бәйле хокук мөнәсәбәтләренә, муниципаль учреждениеләрнең, башка оешмаларның һәм аларның вазыйфаи затларының мөрәҗәгатьләрен карауга бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

1.3. Һәр граждан шәхсән яисә үз вәкиле аша мөрәҗәгать итәргә, шулай ук индивидуаль һәм коллектив мөрәҗәгатьләр, шул исәптән юридик затлар мөрәҗәгатьләрен дә кертеп, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

1.4. Гражданнар мөрәҗәгатькә хокукны ирекле рәвештә гамәлгә ашыралар. Мөрәҗәгатькә хокукны гамәлгә ашыру башка затларның хокукларын һәм ирекләрен бозмаска тиеш.

1.5. Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган төп төшенчәләр «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән мәгънәләрдә кулланыла.

1.6. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлар үз компетенцияләре чикләрендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен кабул итәргә, аларны «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - Федераль закон) «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – Татарстан Республикасы Законы) һәм әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән тәртипкә һәм срокларда карарга, тиешле чаралар күрергә, дәлилле җаваплар бирергә тиеш.

## 2. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау эшен оештыру

2.1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары (алга таба - җирле үзидарә органнары) һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары (алга таба - вазыйфаи затлар) гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эшен оештырырга, мөрәҗәгатьләрне объектив, һәрьяклап һәм үз вакытында карауны, гражданнарны вазыйфаи затлар тарафыннан шәхси кабул итүне, гражданнар мөрәҗәгатьләренең асылы буенча карарлар кабул итәргә хокуклы затлар тәэмин итәргә тиеш.

2.2. Гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча эшләр башка эш башкарудан аерым алып барыла.

Гражданнар үз мөрәҗәгатьләрен карау өчен тапшыралар:

шәхсән җирле үзидарә органына;

Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге Башкарма комитетының җирле үзидарә органы адресына почта юлламасы белән;

гражданнарны шәхсән кабул итү барышында;

җирле үзидарә органы телефоны буенча факсимиль элемтә каналлары буенча 8(85551) 3-66-38;

«Интернет-кабул итү» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районы порталында;

җирле үзидарә органы билгеләгән электрон почта адресына.

2.3. Җирле үзидарә органнарына һәм вазыйфаи затларга язма яисә телдән, шәхси формада бщян ителгән барлык мөрәҗәгатьләр, шулай ук гражданнарның почта, телефакс, телеграф яисә башка юл белән алынган мөрәҗәгатьләре билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

2.4. Язма мөрәҗәгать җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка кергән вакыттан алып өч көн эчендә мәҗбүри теркәлергә тиеш.

2.5. Җирле үзидарә органнары үзләре махсус төзи торган структур бүлекчәләр яисә эшчәнлекләре тиешле нигезләмәләр белән билгеләнә торган махсус билгеләнгән затлар аша гражданнар мөрәҗәгатьләрен кабул итүне оештыралар.

## 3. Гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча эшләрнең ведомствога буйсынуы

3.1. Граждан язма мөрәҗәгатьне мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә кергән органга яисә вазыйфаи затка җибәрә.

3.2. Гражданнар мөрәҗәгатьләре җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлар тарафыннан үз компетенцияләре нигезендә карала.

3.3. Әлеге җирле үзидарәнең органы яисә вазыйфаи зат компетенциясенә кермәгән мәсьәләләрне үз эченә алган язма мөрәҗәгать Федераль законның 11 статьясындагы 4 өлешендә һәм Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 4 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, мөрәҗәгать юллаган гражданга хәбәр итеп, мөрәҗәгать юллаган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә кергән тиешле органга яисә тиешле вазыйфаи затка теркелгән көннән җиде көн эчендә юллана.

3.4. Язма мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү берничә дәүләт органы, җирле үзидарә органнары яисә вазыйфаи затлар компетенциясенә керсә,

мөрәҗәгатьнең күчермәсе теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә тиешле дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә тиешле вазыйфаи затларга җибәрелә.

3.5. Карау өчен шикаятьне карарга һәм гамәлләренә (яисә гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка җибәрү тыела.

3.6. Әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктында каралган тыю нигезендә шикаятьне дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә керә торган вазыйфаи затка карау өчен җибәрү мөмкин булмаган очракта, шикаять гражданга кире кайтарыла һәм аның тиешле карарга яисә гамәленә (гамәл кылмавына) билгеләнгән тәртиптә судка шикаять бирү хокукы аңлатыла.

## 4. Мөрәҗәгатьне караганда гражданның хокуклары

4.1. Мөрәҗәгать җирле үзидарә органы яисә вазыйфаи зат тарафыннан каралганда граждан хокуклы:

1) мөрәҗәгатьне караучы затка дәлилләрне шәхсән үзе бәян итәргә;

2) җирле үзидарә органының тиешле структур бүлекчәсендә яисә тиешле вазыйфаи заттан язма мөрәҗәгатьне теркәү турында, шулай ук аны карау сроклары турында телдән (шул исәптән телефон аша) яисә электрон рәвештә мәгълүмат алырга;

3) мөрәҗәгать кабул иткән органның вәкаләтле заты (вазыйфаи заты) тарафыннан мөрәҗәгатьнең граждан тарафыннан тапшырылган икенче нөсхәсендә датасы һәм номеры күрсәтелгән имза кую юлы белән язма мөрәҗәгатьне кабул итү фактын таныклауга;

4) өстәмә документлар һәм материаллар тапшырырга яки аларны таләп итү турындагы үтенеч белән, шул исәптән электрон рәвештә дә мөрәҗәгать итәргә;

5) әгәр бу башка затларның хокукларына, ирекләренә һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылмаса һәм күрсәтелгән документларда һәм материалларда дәүләт сере яисә федераль закон белән саклана торган башка сер булып торучы белешмәләр булмаса, мөрәҗәгатьне карауга кагылышлы документлар һәм материаллар белән танышырга;

6) мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча язма җавап алырга, Федераль законның 11 статьясында һәм ТР Законының 4 статьясында күрсәтелгән очраклардан тыш, ә Федераль законның 11 статьясындагы 5.1 өлешендә һәм ТР Законының 4 статьясындагы 5.1 өлешендә каралган очракта, аны бирү турындагы үтенеч белән мөрәҗәгать итү нигезендә, - язма мөрәҗәгатьне җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә керә торган затларга;

7) мөрәҗәгать буенча кабул ителгән карарга яисә мөрәҗәгатьне Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә административ һәм (яисә) суд тәртибендә карауга бәйле рәвештә гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять белән мөрәҗәгать итәргә;

8) мөрәҗәгатьне карауны туктату турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә.

4.2. Гражданнар җирле үзидарә органнарына һәм вазыйфаи затларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә, туган телдә яисә Россия Федерациясе халыкларының үзләре белгән теләсә кайсы телендә мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Гражданнарның тәкъдимнәренә, гаризаларына, шикаятьләренә җаваплар мөрәҗәгать

телендә бирелә. Мөрәҗәгать телендә җавап бирү мөмкин булмаган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт телләре кулланыла.

### 5. Гражданның мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә аның иминлеге гарантияләре

5.1. Күрсәтелгән органнарның яки вазыйфаи затның эшчәнлеген тәнкыйтьләп җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка мөрәҗәгать иткәнгә йә үз хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен йә башка затларның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен торгызу яисә яклау максатларында гражданны эзәрлекләү тыела.

5.2. Мөрәҗәгатьне караганда мөрәҗәгатьтәге белешмәләрне, шулай ук гражданның хосусый тормышына кагылышлы белешмәләрне аның ризалыгыннан башка тарату рөхсәт ителми. Мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә керә торган дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язма мөрәҗәгать җибәрү мөрәҗәгатьтәге белешмәләрне тарату була алмый.

### 6. Язма мөрәҗәгатькә таләпләр

6.1. Граждан үзенең язма мөрәҗәгатендә мәҗбүри рәвештә яки язма мөрәҗәгать җибәргән җирле үзидарә органының исемен, яки тиешле вазыйфаи затның фамилиясен, исемен, атасының исемен, йә тиешле затның вазыйфасын, шулай ук үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы - булган очракта), җавап җибәрелергә тиешле почта адресын, мөрәҗәгатьнең адресын күрсәтә, асылын бәян итә: тәкъдимнәр, гаризалар яисә шикаятьләр, шәхси имзасын һәм датасын куя.

6.2. Кирәк булган очракта граждан үз дәлилләрен раслап язма мөрәҗәгатькә документларны һәм материалларны йә аларның күчермәләрен терки.

6.3. Җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгать Федераль законда һәм Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Мөрәҗәгатьтә граждан мәҗбүри тәртиптә үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы - булган очракта) күрсәтә, шулай ук электрон почта адресын күрсәтә йә мөрәҗәгатьне адреслаштыру турында җавап, хәбәрнамә җибәрелергә тиешле бердәм порталда Шәхси кабинет адресыннан (уникаль идентификаторыннан) файдалана. Граждан мондый мөрәҗәгатькә кирәкле документларны һәм материалларны электрон рәвештә теркәргә хокуклы.

### 7. Мөрәҗәгатьне карауга кабул итүнең мәҗбүрилеге

7.1. Җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка аларның компетенциясе нигезендә кергән мөрәҗәгать мәҗбүри рәвештә каралырга тиеш.

7.2. Кирәк булган очракта мөрәҗәгатьне караган җирле үзидарә органы яисә вазыйфаи зат мөрәҗәгатьне урынга чыгып карауны тәэмин итә ала.

### 8. Мөрәҗәгатьне карау

8.1. Җирле үзидарә органы яисә вазыйфаи зат:

1) мөрәҗәгатьне объектив, һәрьяклап һәм вакытында карауны тәэмин итә, кирәк булганда-мөрәҗәгать җибәргән граждан катнашында;

2) мөрәҗәгатьне карау өчен башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм башка вазыйфаи затлардан, судлардан, сорау алу органнарыннан

һәм алдан тикшерү органнарыннан тыш, кирәкле документларны һәм материалларны, шул исәптән электрон рәвештә, соратып ала;

3) гражданның бозылган хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен торгызуга яисә яклауга юнәлдерелгән чаралар күрә;

4) мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча язма җавап бирә, моңа Федераль законның 11 статьясында һәм ТР Законының 4 статьясында күрсәтелгән очраклар керми;

5) гражданга аның мөрәҗәгатен карау өчен башка дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә аларның компетенцияләре нигезендә башка вазыйфаи затка җибәрү турында хәбәр итә.

8.2. Җирле үзидарә органы яисә вазыйфаи зат мөрәҗәгатьне караучы дәүләт органының, җирле үзидарә органының яисә вазыйфаи затның билгеләнгән тәртиптә җибәрелгән гарызнамәсе буенча 15 көн эчендә мөрәҗәгатьне карау өчен кирәкле документларны һәм материалларны тапшырырга тиеш, моңа дәүләт серен яисә федераль закон белән саклана торган башка серне тәшкил итә торган белешмәләре булган һәм бирүнең махсус тәртибе билгеләнгән документлар һәм материаллар керми.

8.3. Мөрәҗәгатькә җавап җирле үзидарә органы җитәкчесе, вазыйфаи зат яисә моңа вәкаләтле зат тарафыннан имзалана.

8.4. Мөрәҗәгатькә җавап электрон документ рәвешендә җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресына яисә гражданның шәхси Кабинеты адресына (уникаль идентификаторына) аннан файдаланганда Бердәм порталда һәм язма рәвештә җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язма рәвештә кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән почта адресына җибәрелә. Моннан тыш, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка кергән, билгесез затлар даирәсе мәнфәгатьләренә кагыла торган тәкъдим, гариза яисә шикаять булган мөрәҗәгатькә, аерым алганда, билгесез затлар даирәсенә карата чыгарылган суд карарына шикаять белдерелгән мөрәҗәгатькә, җавапка, шул исәптән суд карарына шикаять бирү тәртибен аңлатып, Федераль законның 6 статьясындагы 2 өлеше һәм Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 2 өлеше таләпләрен үтәгән килеш «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Кырынды авыл җирлеге битендә «Гражданнар мөрәҗәгатьләре» бүлегендә урнаштырылырга мөмкин.

## 9. Язма мөрәҗәгатьне карау сроклары

9.1. Үз компетенциясе нигезендә җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка кергән язма мөрәҗәгать язма мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып 30 көн эчендә карала.

9.2. Аерым очракларда, шулай ук «Россия Федерациясендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешендә һәм «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясындагы 1 өлешендә каралган гарызнамәне җибәргән очракта, җирле үзидарә органы җитәкчесе, вазыйфаи зат яки ул мөрәҗәгатьне җибәргән гражданны карау срогын озайту турында хәбәр итеп, мөрәҗәгатьне карау срогын кимендә 30 көнгә озайтырга хокуклы.

## 10. Гражданнарны шәхсән кабул итү

10.1. Җирле үзидарә органнарында гражданнарны аларның җитәкчеләре һәм шуңа вәкаләтле затлар кабул итә. Кабул итү урыны, шулай ук кабул итү өчен билгеләнгән көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат гражданнарга җиткерелә.

Гражданнарны кабул итү урыны, кабул итү өчен билгеләнгән көннәр һәм сәгатьләр, гражданнарны кабул итүгә әзерлек өчен җаваплы вазыйфаи затларның контакт телефоннары турындагы мәгълүмат "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша гражданнарга җиткерелә. Күрсәтелгән мәгълүмат шулай ук һәркем өчен мөмкин булган урыннарда җирле үзидарә органнары биналарында урнаштырыла.

10.2. Кабул итүгә язылган һәр гражданга шәхси кабул итү карточкасы тутырыла (1 нче кушымтада билгеләнгән форма), анда:

1) мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта);

2) аның яшәү урыны адресы;

3) кабул итү алып баручы вазыйфаи затның фамилиясе;

4) башка кирәкле белешмәләр күрсәтелә.

10.3. Шәхсән кабул иткәндә граждан аның шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

10.4. Телдән мөрәҗәгатьнең эчтәлеге гражданның шәхси кабул итү карточкасына кертелә. Әгәр телдән мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактлар һәм хәлләр ачык күренеп торса һәм өстәмә тикшерү таләп ителмәсә, гражданның ризалыгы белән мөрәҗәгатькә җавап шәхсән кабул итү барышында телдән бирелергә мөмкин, бу хакта гражданның шәхси кабул итү карточкасына язып куела. Калган очракларда мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча язма җавап бирелә.

10.5. Шәхсән кабул итү барышында кабул ителгән язма мөрәҗәгать Федераль законда һәм ТР Законында билгеләнгән тәртиптә теркәлергә һәм каралырга тиеш.

10.6. Мөрәҗәгатьтә хәл ителеше җирле үзидарә органы яисә вазыйфаи зат белешмәләре компетенциясенә керми торган мәсьәләләр булган очракта, гражданга кая һәм нинди тәртиптә мөрәҗәгать итәргә кирәклеге аңлатыла.

10.7. Шәхсән кабул итү барышында гражданинга мөрәҗәгатьне алга таба караудан баш тартылырга мөмкин, әгәр аңа мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча элегрәк җавап бирелгән булса.

10.8. Гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә җирле үзидарә органнарында беренче чиратта шәхси кабул итү хокукына ия булалар:

1) I, II төркем инвалидлар һәм (яисә) аларның законлы вәкилләре (ата-аналарның, уллыкка алучыларның берсе, опекун яисә попечитель);

2) Бөек Ватан сугышы ветераннары, Россия Федерациясе Геройлары, Советлар Союзы Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе Геройлары, сугышчан хәрәкәтләр ветераннары;

3) махсус хәрби операциядә катнашучы һәм катнашкан гражданнар һәм махсус хәрби операциядә катнашучы һәм катнашкан гражданнарның гаиләләре (гаилә әгъзалары);

4) инвалид балалар, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар, шулай ук аларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре, әгәр алар мондый

балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр;

5) өч яшькә кадәрге балалар белән кабул итүгә килгән гражданнар.

6) үз эшчәнлеге мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе сенаторы, Дәүләт Думасы депутаты.

10.9. Беренче чиратта шәхси кабул итү хокукына бер үк вакытта берничә граждан ия булган очракта, күрсәтелгән гражданнарны кабул итү аларның шәхси кабул итүгә килү тәртибендә гамәлгә ашырыла.

10.10. Әлеге Нигезләмәнең 10.8 пунктында күрсәтелгән гражданнар шәхсән кабул иткәндә беренче чиратта шәхси кабул итүгә хокукларын раслый торган документ күрсәтәләр.

## 11. Коррупция юнәлеше фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү

11.1. «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә гражданнар җирле үзидарә органнарына һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларына коррупция юнәлеше фактлары буенча мөрәҗәгатьләр җибәрергә хокуклы.

11.2. Коррупция юнәлеше фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләренә коррупция һәм янап куркытып алу фактлары турында белешмәләр, хезмәт тәртибенә таләпләрне бозу, шулай ук вазыйфаи затларның хезмәт урыныннан явызларча файдалану билгеләре булган башка гамәлләр кылуны үз эченә ала.

11.3. Кергән мөрәҗәгатьтә әзерләнә торган, башкарыла торган яисә кылынган хокукка каршы гамәл турында, шулай ук аны әзерләүче, башкаручы яисә кылган зат турында белешмәләр булганда, мондый мөрәҗәгать хокук саклау органнарына җибәрелә.

11.4. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүче вазыйфаи затлар билгеләнгән тәртиптә хезмәт мәгълүматының һәм конфиденциаль характердагы белешмәләрнең сакланышы өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә персональ җаваплылык тоталар.

11.5. Гражданнар коррупция юнәлеше фактлар буенча мөрәҗәгатьләрен караганда, мөрәҗәгатьләрдәге белешмәләрне аның ризалыгыннан башка тарату рөхсәт итилми. Карала торган мәсьәләнең барлык шартлары ачыкланганчы мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә кергән вазыйфаи затка язма мөрәҗәгатьне җибәрү мөрәҗәгатьтәге беоешмәләрне фаш итү булып саналмый.

11.6. җирле үзидарә органнарына һәм вазыйфаи затларга кергән коррупция юнәлеше фактлар буенча гражданнарның мөрәҗәгатьләре әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш.

## 12. Мөрәҗәгатьләрне карау тәртибенең үтәлешен тикшереп тору

12.1. Җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлар үз вәкаләтләре чикләрендә мөрәҗәгатьләрне карау тәртибенең һәм срокларының үтәлешен, мөрәҗәгатьләргә язма җаваплар җибәрелүен тикшереп торалар, кабул ителә торган мөрәҗәгатьләрнең эчтәлеген анализлыйлар, гражданнарның хокукларын, ирекләрен һәм законлы

мәнфәгатьләрен бозу сәбәпләрен вакытында ачыклау һәм бетерү буенча чаралар күрәләр.

## 13. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турындагы законнарны бозган өчен җаваплылык

13.1. «Россия Федерациясе гражданнарының һәм «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе хакында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законны бозуда гаепле затлар Россия Федерациясе законнарында каралган җаваплылыкка ия.

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүнең 20.03.2025 елның 52-2 номерлы карары белән кабул ителгән тәртибенә 1 нче кушымта

УЧЕТНАЯ КАРТОЧКА № ______ ЛИЧНОГО ПРИЕМА ГРАЖДАН

_____________________________________________

Дата приема "____" __________ 20___ г.

Время приема ______ час. ______ мин.

Место проведения приема: _____________________________________________

Ф.И.О. должностного лица, ведущего прием:____________________________

_________________________________________________________________________

| | |
|---|---|
| Ф.И.О. гражданина, представителя организации | |
| Адрес места жительства и телефон заявителя | |
| Род занятий, место работы | |
| Краткое содержание вопроса | |
| Поручение (кому) | |
| Сроки исполнения, данные о продлении | |
| Результаты рассмотрения заявления | |